# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Щәдче авыл җирлеге составына керүче Юкәче торак пунктында үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 10 «30»октябрь, 2024 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчестатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенең Юкәче торак пунктында 2024 елның 30 октябрендә узган үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Юкәче торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 төркем инвалидлар, хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, махсус хәрби операцияда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары ( хатыны һәм 18 яшькә кадәр булган балалары), көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- торак пункт территориясен төзекләндерү: Юкәче торак пунктында ял итү һәм башка культуралы чаралар үткәрү өчен ял итү мәйданчыгы урнаштыру (материаллар сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү);

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту: Юкәче торак пунктында юлларны тигезләү һәм кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);

-Юкәче торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү(агымдагы ремонт, урамнарны яктырту лампаларын сатып алу һәм алыштыру)):

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыендакатнашучылар исемлегенә 138 кеше кертелгән;
гражданнарҗыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 89 кеше, 64,5% тәшкил итә.

Гражданнарҗыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 89 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ»позициясе өчен  0 граждан тавыш бирде;
Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенең Юкәче торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенең Юкәче торак пунктында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга:«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Юкәче торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 төркем инвалидлар, хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары ( хатыны һәм 18 яшькә кадәр булган балалары), көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзарасалым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- торак пункт территориясен төзекләндерү: Юкәче торак пунктында ял итү һәм башка культуралы чаралар үткәрү өчен ял итү мәйданчыгы урнаштыру (материаллар сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү);

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту: Юкәче торак пунктында юлларны тигезләү һәм кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);

-Юкәче торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү(агымдагы ремонт, урамнарны яктырту лампаларын сатып алу һәм алыштыру)).

3. Әлеге карарны Шәдче авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнарҗыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.В.Шрыков